# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“15” ноябрь 2019 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 15 ноябрендә «Сез 2020 елда Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган тубәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- Иске Җогып торак пунктында балалар уен мәйданчыгына җиһаз алу һәм урнаштыру;

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 115 (бер йөз унбиш) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 84 (сиксән дүрт) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 84 (сиксән дүрт) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.
2. “Сез 2020 елда Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогыпторак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган тубәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме: - Иске Җогып торак пунктында балалар уен мәйданчыгына җиһаз алу һәм урнаштыру” мәсьәләсен кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогыпавылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.